**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 19 июнь № 391

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибе турында» 2011 ел, 12 август, 660 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибе турында» 2011 ел, 12 август, 660 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм аларны туктату тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктта:

1 пунктчага «, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектына һәм аның яр буе полосасына ачык керә алуын тәэмин итү максатларында» сүзләрен өстәргә;

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җир кишәрлегендә межа билгеләре, дәүләт геодезия челтәрләренең геодезия пунктлары, гравиметрия пунктлары, нивелир пунктлар һәм аларга керү урыннарын урнаштыру;»;

8 пунктчага «, аквакультура (балыкчылык)» сүзләрен өстәргә;

10 пунктча үз көчен югалткан дип санарга;

16 нчы пунктның беренче абзацында «җир кишәрлегенең кадастр паспортына» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына» сүзләренә алмаштырырга;

17 нче пунктның өченче абзацында «Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрында» сүзләрен «Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\391.docx